
*Түбән Табын мәктәп-интернаты гәҗите*

# ТЕЛ.МИЛЛӘТ.ИҖАТ

АПРЕЛЬ, 2021 НЧЕ ЕЛ.




**Тел.Милләт. Иҗат**

Кечкенәдән үк күңелемә урнашкан җырулар сөймәкемнән миндә туган телебезне сөю тугъды. Әгәр миңа җырулар ярдәм итмәсә, мин соң... туган телебезне сөймәк кеби бер олугъ нигъмәткә малик була алыр идеммени? Яшәсен халык әдәбияты, яшәсен туган тел /Г.Тукай/

Һәр кешенең беренче көннән үк туплый башлаган хәзинәсе – туган тел. Һәр милләт кешесе өчен иң матур, иң кадерле тел – үзенең туган теле. Бөтен дөнья халыкара аралашу теле дип саналган 14 телнең берсе. Татар телендә аралашабыз икән, димәк, татар милләте, иҗаты яши, үсә. Милләтебезнең югалмавы, телебезнең үсүе безнең кулда. Һәр кеше өчен иң якыны, иң мөһиме – ул туган теле! Минем туган телем – татар теле, Туган телебезгә дан җырлаучы язучыларыбыз һәм шагыйрьләребез бик күп. Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Һади Такташ, Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Гадел Кутуй ,Фоат Садриев һәм бик күп башка әдипләребез. Аларның әсәрләре аша без туган телебезнең бөеклеген, затлылыгын аңлыйбыз. Матурлыгына, гүзәллегенә сокланып туя алмыйбыз.Туган тел! Бу сүз һәркем өчен кадерле, газиз! Ул ватан, туган җир, ата- ана сүзләре белән бергә торган бөек, изге һәм кадерле сүз!Минемчә, туган телне яратуны шагыйребез Г. Тукай тулысынча аңлатып биргән. “Туган тел” шигыре кешене тормышның бөтен чорларына алып кайта. Сиңа гомер бүләк иткән эти-әниеңнең теле аша син дөньяны таныгансың. Башка телләр үзләренчә матур булса да, үз телеңнең яңгырашы үк башка. Ул сиңа үгет-нәсыйхәт тә ишетелә.Туган телең аша җирдәге, кешедәге матурлык бөтен тулылыгы белән аңлашыла.Җырларыбызга моңлылык хас булган кебек, телебезгә дә моңлылык хас. Ә моң кешенең йөрәгендә, күңел түрендә туа. Моңлы халык начар була алмый.

*Бу санда:*


| | |
|---|---|
| ТЕЛ.МИЛЛӘТ.ИҖАТ | 1 |
| УКУЧЫЛАР ИҖАТЫ | 2 |
| КӨН ҮЗӘГЕНДӘ. | 3 |
| ФОАТ САДРИЕВ-ТАТАРНЫҢ ШОЛОХОВЫ | 4 |
| ЯЛ ИТКӘН АРАДА | 5 |
| ТУГАН ТЕЛЕМ-ИРКӘ ГӨЛЕМ | 6 |

# УКУЧЫЛАР ИҖАТЫ



Минем туган татар телем чынлап та бик матур. Ул минем өчен әнием һәм әтием кебек якын, кадерле.Минем туган телем – татар теле. Без татар теле дәресләрендә матур итеп сөйләшергә, дөрес итеп язарга өйрәнәбез. Туган телебезнең матурлыгын, байлыгын күбрәк тоябыз. Һәр кеше үз туган телен яратсын һәм үз туган телендә сөйләшсен иде.

Усанова А., 4

**Чәй өстәле артында**

Чәй өстәле әзерлибез
Тәмле ипи куябыз,
Эх, чәе дә чәе!
Үләннән шул чәе.
Әни тәлинкәләр тезә
Җитсен дип, безгә.
Апа калак алып килә
Ә апаем көлә.
Чәй өстәле әзер
Җыелабыз хәзер.
Түгәрәктер өстәлебез,
Шаттыр йөзебез,
Гаилә белән гөрләшеп
Чәй эчәбез хәзер без.

Харисова Алсу

**Безнең авыл**

Тукай авылы Кырлай булса,
Безнеке Мөслим була.
Үзгәрешләр күп булса да,
Исемнәре шул кала.
Электән үк яшәп килә
Бай тарихлы авылым.
Авылыңны үз итә алсаң
Куркытмас яшен-давылы.
Туган авылым гөрләп яши,
Яшәсен һәрчак шулай.
Кирәк чакта ярдәм итәр,
Үз авылым – тәүге терәк.

Мубараков Гадел

**Мин бәхетле бу дөньяда**

Бәхетле мин бу дөньяда
Җир йөзенә туганга.
Әти-әни һәм абыем
Янәшәдә булганга.
Язсын ходай җир йөзендә
Тату гомер итәргә.
Тигез гомер, сау-сәламәт
Гомер көзен сүтәргә.

Байгузин Артем.

**Мин бәхетле бу дөньяда**

Бәхетле мин бу дөньяда
Җир йөзенә туганга.
Әти-әни, туганнарым,
Янәшәмдә булганга.
Язсын ходай җир йөзендә
Тату гомер итәргә.
Тигез гомер, сау-сәламәт
Гомер көзен сүтәргә.

Салимова Инзилә

**Ямьле яз**

Менә ямьле яз да килеп җитте. Кояш тагын да ныграк җылыта. Көннәр озыная, төннәр кыскара. Табигатьнең шул билгеләрен кошлар да белә, туган якларына кайта башлыйлар.

Беренче булып кара каргалар кайтты. Кайтуга оя ясый башладылар. Тиздән балалары да чыгар. Каргалар артыннан сыерчыклар кайттылар. Алар кешеләр ясаган ояларга кереп оялыйлар. Матур итеп сайрыйлар. Кошлар бик файдалы. Алар зарарлы бөҗәкләрне юк итәләр.
Безнең якның табигате бик матур.Шуңа күрә кошлар да бик күп.

Давлетов Д.

# *КӨН ҮЗӘГЕНДӘ ...*

Укучыларны халкыбызның йөрәк түреннән шытып чыккан җәүһәрләре – әкиятләре белән таныштыру, әкиятләрнең эчтәлеген һәм тәрбияви үзенчәлекләрен ачыклау, татар халык әкиятләренә мәхәббәт тәрбияләү максатыннан, мәктәп волонтерлары "Әкият геройлары-бездә кунакта" исеме астында тәрбияви чара



уздырдылар. Сөйкемле Шүрәле, ягымлы Убырлы карчык, Җен малае чараның төп кунаклары булдылар. Укучылар белән татар халык әкиятләрен, табышмаклар искә төшереп үттеләр. Чара дәвамында шулай ук Убырлы карчык әкият укыса, Шүрәле әфәнде мавыктыргыч "Нәрсә ул кем белә?"уенын да уйнатты.

***

2021 ел Татарстанда Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан ителде. Шул уңайдан мәктәбебездә укучылар һәм укытучылар көче белән «Милли почмак» булдырылды.






Якташыбыз,халык язучысы Фоат ага Садриев быел үзенең күркәм 80 яшьлек юбилеен билгеләп узды.Әлеге вакыйга уңаеннан китапханәче Халимова Г.М. укучыларны , әдип иҗаты белән якыннан таныштыру максатыннан укучылар өчен «Олуг әдип» исеме астында тәрбия сәгате һәм китап күргәзмәсе оештырды. Әлеге чарада укучылар әдипнең тормыш юлын белән якыннан танышып, әсәрләренә күзәтү дә ясадылар

***



Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы, бөек шагыйрь Габдулла Тукайның 135 яше тулу уңаеннан 1– 9 сыйныф укучылары арасында «Тукай әсәрләре минем иҗатымда» исеме астында рәсем конкурсы уздырылды. Нәтиҗәләр ясау барышында тематикага туры килү, башкару сыйфаты,иҗади карарның оригинальлеге,бизәлешнең төгәллеге искә алынды.

***

Туган телләр хәм халыклар бердәмлеге елы кысаларында татарнын прозаигы, якташыбыз Фоат Садриевның 80 яшьлек




юбилее уңаеннан мәктәбебездә әдәби кичә узды. Кичәдә тормыш юлы, иҗаты белән таныштырылды. Балалар өчен язылган әсәрләре укылды. Сәхнә әсәреннән өзек каралды

***

.Апрель ае - Тукай ае. Ул - бөек шагыйрьне тудырган ай. Бу айда күп төрле чараларның уздырылуы - шуның ачык мисалы.Мәктәпләрдә татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайның туган көнен билгеләп үтү инде традициягә әйләнде. Без иң элек балаларны аның тормыш юлы, ятим бала чагы белән таныштырабыз. Төрле альбомнар, презентацияләр карыйбыз. Аннан соң нәниләр күңелен шигърият били.

## *ЯЛ ИТКӘН АРАДА.*

Дускай! Син Тукай абыйның шигырь- әкиятләрен яхшы беләсеңме? Сорауларны игътибар белән укып, Габдулла Тукай биографиясе буенча белемнәреңне ныгытырсың.



**Вертикаль буенча**

1. Г.Тукайның туган авылы.
3. Әнисенең исеме.
5. Тукайның соңгы көннәре кайсы шәһәрдә үтә?
8. Уральскида укыган мәдрәсә.
9. Г.Тукайның иң якын дусты.

**Горизонталь буенча**

2. Г.Тукайның әтисенең исеме.
4. Кечкенә Апушны нинди базардан асрамага биреп җибәрәләр?
5. Кайсы авыл Тукайның шагыйрь булуында зур роль уйный?
6. Кайсы газетада наборщик булып эшли?
7. 1905 нче елны кайсы журналда Тукайның шигырь җыентыгы басыла?

### Фоат Садриев һәм Габдулла Тукай әсәрләре буенча ребус.



## ТУГАН ТЕЛЕМ-ИРКӘ ГӨЛЕМ.
## АТАКЛЫ КЕШЕЛӘРНЕҢ ТЕЛ ТУРЫНДА ӘЙТКӘН СҮЗЛӘРЕ

Кешелек әле милләтнең төп таянычы булган, йөрәк парәседәй нечкә, кадерле башка төр могҗизаны уйлап тапмаган, таба да алмас, бу бөек көчне бернәрсә дә алыштыра алмый. Чыгышы белән татар булса да, үз телен белмәгән, шул ук вакытта үз халкын яраткан, аны сөйгән кеше дә милләтнең сакчысы, аның үсешенә өлеш кертә алган зат була алмый...

Ә. Кәримуллин

Туган тел ул тәндә, җанда калсын,
Ана сөте булып гомергә.

**Илдар Юзеев.**

Уе юкның- теле юк,
Теле юкның - иле юк.
Илен санга санамаган
Телсездән дә тиле юк.
***Нури Арсланов***

Кешеләрнең яшәеше тел белән бәйләнгән.

***Жорж Батай***

Нинди дә булса халыкның гореф-гадәтләрен белергә теләсәң, аларның телен өйрән.
**Пифагор**

Әгәр дә милләтне көчле итеп, бөек итеп күрәсең килә икән, иң беренче булып аның көчен таны, шул милләтнең баласы булуың белән горурлан.

***Туфан Миннуллин***


**«Мизгел»**
**(махсус сан)**
Апрель , 2021нче ел

**Баш мөхәррир:** Хабибуллин И.Р.
**Мөхәррир:** Әхматова Г.В.
**Компьютерда җыючы:** Мубараков А., Мигманова А.
**Корректор:** Сайфуллина Г.Ф.

**Гамәлгә куючы:**
Мөслим интернат мәктәбе
**Адрес:** Мөслим районы,Түбән Табын ,Школьная урамы,40а
**Электрон адрес:** stoy.mus@tatar.ru